# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылы торак пунктында
2023 елда үзара салым кертү турында

**2022 елның 23 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлегенең Зур Нөркәй авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Зур Нөркәй авыл җирлеге территориясендә 1 төркем инвалидлар, көндезге уку йортлары студентлар, дүрт һәм аннан да күбрәк бала белән күп балалы гаиләләр, хөкем ителгәннәр, Украина территориясендә махсус хәрби операция катнашучылар һәм гаилә әгъзаларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. махсуслаштырылган техниканы карап тоту «Беларус-82.1» тракторы (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүче хезмәтенә түләү);
2. Зур Нөркәй авылында урам яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (урам яктырту утларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырту челтәрләрен карап тоту һәм аларга техник хезмәт күрсәтү);
3. Зур Нөркәй авылында җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү) ;
4. Зур Нөркәй авылында бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр сатып алу (Сабантуй, 9 Май, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне);
5. Зур Нөркәй авылы территориясендә көнкүреш калдыклары һәм чүп чар вакытлыча җыела торган урыннарны җыештыру (килешү буенча хезмәтләр өчен түләү);
6. «Сарман» район газетасында некрологлар бастыру;
7. Зур Нөркәй авылында С.Рәфыйков урамындагы авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш салу белән чокырларны ремонтлау, таш ташу) ;

8. Зур Нөркәй торак пунктында янгын гидранты сатып алу һәм урнаштыру.

2. Әлеге карарны Зур Нөркәй авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче Р.М.Гайсин